**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 20-40 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә күпкатлы торак төзелеше территориаль зонасы (Ж4) (46 номерлы контур) һәм иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы (ОП) (93 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 28 гыйнварындагы 63 номерлы карары нигезендә, Казаш шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 июнендәге 1717 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә күпкатлы торак төзелешенең территориаль зонасы (Ж4) (46 номерлы контур) һәм иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы (ОП) (93 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында Казан шәһәре Думасы карары проектын әзерләү хакында»гы карарын исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә территориаль зона – иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы (ОП) (93 номерлы контур) чикләренә 16:50:000000:37006 кадастр номерлы җир кишәрлеген кертеп, территориаль зона – күпкатлы торак төзелеше зонасы (Ж4) (46 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә;

1.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составында шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның территориядән югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплеслы үстерү күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.3. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.4. Кагыйдәләрнең 2 номерлы кушымтасына әлеге карарның 3 номерлы кушымтасы нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 12 августындагы
20-40 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОП - 93**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
|---|---|---|
| | Ж4 | Күпкатлы торак төзелеше зонасы |
| | ОП | Иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чикләре |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**